Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

Ислам Нуры

№ 11 (639) 8 июнь, 2017 ел (1438, Рамазан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+

# Быелгы дин әһелләре форумы чараларга аеруча бай булды

18-20 майда Казанда татар дин әһелләренең “Милли тормыш һәм дин” дип исемләнгән VIII Бөтенрусия форумы узды. Анда 68 төбәктән 965 вәкил катнашты. Быелгы форум да зур дәрәҗәдә үтте. Аның эшендә Татарстан президенты Рөстәм Миннеханов, Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, премьер-министр Алексей Песошин, Бөтендөнья татарлары Башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Закиров, мөфтиләр Камил хәзрәт Сәмигуллин, Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Рәсәй мөфтиләре Шурасы рәисе урынбасары Рушан Аббясов һ.б.лар катнашты. Форумда динебез һәм милләтебез киләчәгенә кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышынды. Мәсәлән, дин әһелләрен җәдитчелек традицияләрендә тәрбияләү, татар эшмәкәрләре белән бергә хосусый татар мәктәпләрен, балалар бакчаларын ачу, бала туу, гаилә төзелү, җеназа очракларын мәчетләрдә кенәгәләргә теркәп бару, татарларның демографик базасын булдыру, “Мөселманнар” тапшыруын Федераль каналга кире кайтару, мөселманнар эзәрлекләнгән очракта аларны яклау һ.б. мәсьәләләр күтәрелде.





Форумда аерым дин әһелләренә Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре тапшырылды. Мәсәлән, Мордовия укытучыларының яулык бәйләп эшкә йөрү хокукын яклаган адвокат Марат Ашимовка Бөтендөнья татар конгрессы медале тапшырылды, Башкортостанның Балтач районы имам-мөхтәсибе, райондагы “Батырша” музее директоры Рафис хәзрәт Шәйхәйдаровка “Татарстанның Атказанган мәдәният хезмәткәре” исеме бирелде.

Быелгы форум олы чараларга аеруча бай булды. Форум кысаларында 18 майда “Корстон” кунакханәсе комплексы каршындагы махсус чатырда RUSSIA HALAL EXPO күргәзмәсе ачылды. Аның эше белән Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов, Республика азык-төлек министры Марат Әхмәтов та таныштылар. Күргәзмә ачылышында чыгыш ясап мөфти Камил хәзрәт Исламча яшәү рәвешен тормышка кертү, сәламәтлегебезне саклау өчен мондый чараларның бик әһәмиятле булуын билгеләде. Күргәзмә 20 майга кадәр эшләде. Аның эшендә хәләллек өлкәсе белән бәйле 60 якын оешма, алар арасында чит ил компанияләре дә катнашты. 19 майда Казан кирмәнендә 1977 елда табылган һәм тарих институтының археология бүлегендә сакланган Казан ханнары Мәхмәд һәм Мөхәммәдәмин җәсәдләрен җеназа укып җирләү булды. 20 майда делегатлар Болгар җыенында катнаштылар, биредә сентябрь аенда эшли башлаячак Болгар академисе бинасы, башка истәлекле һәйкәлләр белән таныштылар.

# “Хәзинә” клубы 5 еллыгын билгеләде



Мөселман балаларының Чаллы мөхтәсибәте каршында эшләүче “Хәзинә” клубы 20 майда үзенең 5 еллык юбилеен билгеләп үтте. Төп чара шәһәрнең 2 нче санлы татар гимназиясе актлар залында барды. Биредә клубка йөрүче балалар үзләренең дини белемнәрен, туган телне белу дәрәҗәләрен күрсәттеләр. Тамаша композиясе сәхнә күренешләренә бай итеп төзелгән, анда һәр балага бер аерым роль бирелгән иде. Балалар Коръән дә укыдылар, тәсбих тә тарттылар, балага исем кушу йоласын да башкардылар, чыгарылыш төркемен дә зурлап озаттылар. Чыгышлар арасында клуб тормышыннан видеосюжетлар күрсәтелде.

Клуб җитәкчесе Ләйсән Рамил кызы Әхмәтшина оешу тарихына тукталып болай диде: “Эшне балаларның җәйге лагерыннан башладык. Аны зур теләк, ихласлылык белән башкардык. Моны күргән ата-аналар балалары белән ел әйләнәсендә эшләвебезне теләделәр. Аларның безгә ышанычын, өмет белән каравын акларга кирәк иде. Чөнки мәчетләрдә кечкенә балалар белән эшләү авыр — алар әлкәннәргә комачаулык итәләр. Клуб шулай барлыкка килде. Әлбәттә, кыенлыклар да булды, бина таба алмыйча йөрдек. Сидоровка бистәсендәге “Ихлас” мәчете имам-хатыйбы Илназ хәзрәт мәчет мәдрәсәсе бинасына сыендырды. Икенче бинабызны эшмәкәр Марсил Мирзанур улы бирде. Хәзер ике бинада 11 төркемебез эшли. Балалар белән эшләүгә 20дән артык хезмәткәр — мөгаллимнәр, тәрбиячеләр, бала караучылар җәлеп ителгән.”

Клубка 1-2 яшьлек балалардан алып 13 яшькә кадәргеләр шөгыльләнә. Мәсәлән, 1-2 яшьлек сабыйларга ана телендә үстереш дәресләре бирелә. 2-3, 3-4 яшьлекләр Ислам дине нигезләрен өйрәнәләр. Аннан өлкәнрәкләр “Мин динемне яратам” программасы буенча укый. Дәресләр яңача методикаларга таянып уеннар белән бергә бәйләп алып барыла. “Мин динемне яратам” программасы буенча Минзәлә районы Яңа Байлар авылында җәйге айларда шөгыльләнүче төркем дә бар. Клубта тәрбияләнүчеләр, мөгаллимәләр республика, шәһәр күләмендә узган бәйгеләрдә призы урыннар яулыйлар.

Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе урынбасары Илназ хәзрәт Яхин чарада чыгыш ясап болай диде: “Мондый клублар әле республикабызда юк дәрәҗәсендә. Ләйсән ханымның бу башлангычы (ул үзе шәһәребезгә бер хәзинә) һәряклап хуплауга, яклауга мохтаҗ. Мин бүгенге юбилейны шундый чакыру дип тә кабул итәм.”



Чара барышында балаларга истәлекле бүләкләр, ә клуб хезмәткәрләренә Чаллы мөхтәсибәтенең Рәхмәт хатлары, чәчәк бәйләмнәре тапшырылды. Аннары күңелле чәй эчү мәҗлесе булды.

**Рәсемнәрдә:** юбилей чарасыннан күренешләр.

# Халкыбызның атаклы дин эшлеклесе Г. Баруди

***Халкыбызның атаклы дин эшлеклесе Галимҗан Баруди турында сөйләп үтәсем килә. Аның тормышы Юныс пәйгамбәребез тормышына охшаш.***

Галимҗан Баруди бай сәүдәгәр гаиләсендә туа, әмма аңа карамастан, ул әтисенең эзе буенча китми. Биш яшеннән динебез шәригатен өйрәнү белән мәшгуль була. Казанның их яхшы уку йортларыннан саналган мәдрәсәне бик яхшы билгеләргә тәмамлый, аннан шул чорда дөньяда иң яхшы дип саналган “Гарәпләр дөньясы” дип аталган мәдрәсәгә юл тота. Ул бу мәдрәсәне дә алдынгы билгеләргә тәмамлый. Аннан башка илләрдә дә аның килүен шатланып көтеп торуларына карамастан, туган иленә, авырлыклар көтеп торган патша Рәсәенә кайтып, Казанда дин белеме бирә башлый.

Ватанына кайткач, әтисе белән бергәләп “Мөхәммәдия” мәдрәсәсен ача Баруди, һәм 30 ел гомерен шушы мәдрәсәдә белем бирүгә багышлый. Татар халкының белем дәрәҗәсен күтәрү өчен, укыту өлкәсендә төрле яңарышлар, үзгәрешләр кертә. Ул беренчеләрдән булып мәдрәсәдә дөньяви белемнәрне дә укыта. Бу мәдрәсәдә медицина, физика өлкәсендә иң абруйлы белгечләр укыта. Ә ислам фәннәренә кагылганда, әйтеп тә торасы да юк инде.

Елдан-ел мәдрәсәнең бинасы яңа корпуслар, аудиторияләр белән зурая бара. Мәдрәсәнең даны ераkларга тарала. Рәсәйнең төрле төбәкләреннән монда белем алу өчен абитуриентлар агыла башлый.

Мөхәммәдиядә 500 гә якын шәкерт белем ала, 20 мөгаллим белем бирә. Монда 19 нчы гасыр ахыры, 20 нче гасыр башларындагы татар интеллигенциясенең иң атаклы галимнәре шәхес булып формалаша.

Әмма нинди авырлыклар үтәргә туры килә аңа!! Күпме көч куярга туры килә! Нинди бәя белән ирешә соң ул бу дәрәҗәгә?! Күп кенә кешеләргә аның эшчәнлеге ошамый. Аннан зарланып, шикаятьләр язалар. Кайберләр аңа “дин кануннарына каршы” кеше ди, бүтәннәре “милләтенең сатлыкҗаны” ди, ә башкалары “галим” һәм “мәгърифәтче” диләр. Өстенә килгән шикаятьләр эзсез үтми, үз эшен эшлиләр. 1908 нче елны Министрның әмере буенча, аны Вологда шәһәренә өч елга сөргенгә җибәрәләр. Анда бераз вакыт торгач, җәза йөзеннән аны тагын Бейрут һәм Дамаск шәһәрләренә өч елга сөрәләр.

Күз алдыгызга китереп карагыз... Үз халкына никадәр яхшылыклар эшләгән инсан, аларга гыйлем биргән, алар өчен мәдрәсә ачкан... Берничә буын зыялы затларны тәрбияләгән. Үзе үк тәрбияләгән кешеләре анардан ваз кичә. Шикаять итәләр. Чит илдә булганда, аның анда калырга мөмкинчелекләре бар иде. Анда аның галим дәрәҗәсен таный иделәр. Әмма 1910 нчы елда ул кире кайта. Ул үзенең халкына һаман ышануын югалтмый. Үзенең милләтенә булган өметен өзми ул.

Кайткач та аны күзәтүләр туктамый, һаман дәвам итә. Шул заман ул императорга хат яза: “Минем үз тормышымнан зарланырга хакым юк. Бу авырлыкларны бары Раббым миңа насыйп иткән. Әмма миңа һаман-һаман саен мөселманнарның беркемгә дә зыян китерергә теләмәүләрен исбат итүе бик авыр. Миңа килгәндә, әтиемнең сәүдәгәрлек эшенә битараф калып, үземнең 50 ел гомеремне китаплар артында үткәрдем. Инде актык көннәремне дә шул бөек хезмәтемә багышлыйсым килә.

Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул кыла һәм бөтен калган гомерен ул укытучылык хезмәтенә багышлады. Бер мең тугыз йөз унҗиденче елда аны Мөфти итеп сайлыйлар. Соңрак Аллаһы Тәгалә аңа тагын сынау җибәрә. Илдә кискен үзгәрешләр башлана. Октябрь инкыйлабы. Меңләгән кешеләр үз диннәреннән баш тарталар. Мәчет, мәдрәсәләр ябыла. Күп кенә кешеләр үз диннәрен саклап калу өчен, чит илләргә качып китәләр. Галимҗан Баруди да китәргә карар кыла, әмма ярты юлда үз фикереннән ваз кичә һәм кире кайта. Ул үзенең халкын, шәкертләрен , шундый авыр минутларда ташлый алмый.

Мөфти булып Баруди 4 ел хезмәт итә. 1921 нче елда, Идел буйларында бик куркыныч ачлык башлана. Галимҗан Баруди халкына ярдәм сорап Мәскәүгә, Сталин янына бара. Сталин ярдәм итәргә сүз бирә. Әмма Баруди Сталинның ярдәм иткәнме, юкмы икәнлеген белә алмый, икенче көнгә ул кисәк кенә бик каты авырып, 64 яшендә вафат була.

Мәшһүр татар галимебезнең тормыш юлы шулай үтә. Үзенең гомерен шәригать гыйлемен өйрәнүгә һәм халкын дингә өйрәтүгә багышлаган татар галимебезнең тормыш юлы шулай уза. Бала чагыннан алып, ахыргы сулышына кадәрле ул Аллаһка карата тугры була һәм Аллаһ та аңа тугры була.

Аллаһ әйтә: “Йә, Аллаһка иман китерүчеләр, Аллаһтан куркыгыз һәм хакыйкатьтә булучылар белән бергә булыгыз”.

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының “Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы.**

# Сорау вә җавап

*Әссәләмүгаләйкүм, хөрмәтле редакция!*

**Минем сорауларга җавап язсагыз мин бик рәхмәтле булыр идем.**

**1. Коръәндә намазларны вакытында укырга кирәк диелә. Бу намаз вакыты кергәч тә укырга кирәк дигән сүзме? Соңгарак калып укылса гөнаһлы булмыйбызмы?**

**2. Җеназа намазына хатын-кызлар катнаша аламы?**

**3. Имам сайлаганда хатын-кызлар катнаша аламы?**

**Җавапларыгыз өчен рәхмәт яусын.**

**Хаҗиев Мөдәррис.**
**Сарман авылы.**

1. Һәр биш намазның үз вакыты бар. Намазның вакыты иркен – аның кергән вакыты бар һәм чыккан вакыты. Һәм ул шәригатьтә билгеләнгән. Һәр кеше намаз вакыты кергәч намаз вакыты чыкканчы укыса шушы намаз вакытында укылган санала һәм дөрес була. Ләкин әле менә шушы дөрес булудан башка, мөстәхәб – яхшырак вакытлар бар, һәм мәкрүһ – начарырак вакытлар бар. Мәсәлән, иртәнге намазның яхшырак вакыты яктыргачырак уку. Ләкин кояш чыгар алдыннан уку, мәсәлән, кояш чыгарга 5-10 минут кына кала уку – ансы инде мәкрүһ вакытка әйләнә. Алай соңга калдыру гөнаһ була.

Өйлә намазының вакыты зәвалдән соң керә һәм икенде намазына хәтле. Хәнәфи мәзһәбендә өйлә намазын көзге-кышкы чорда вакыты керү белән уку яхшырк санала. Әмма җәйге чорда челлә вакытында соңгарак калдырып уку мөстәхәб. Ләкин инде менә-менә вакыты чыга дигән вакытта уку – ансы инде мәкрүһ була.

Икенде намазын шулай ук соңрак вакытта уку яхшырак санала. Ләкин кояш зурая башлагач уку – ансы мәкрүһ. Шуңа күрә дә инде яхшырак вакытында укырга кирәк, ләкин инде артык соңга калдырып түгел. Вакыты чыкканга хәтле кичектерү ярамый.

Ә ахшамны һәрвакытта да вакыты керү белән уку яхшырак, ягъни кояш баю белән. Әмма менә-менә ястү керә дигәндә уку мәкрүһ була.

Ястү намазын төннең өчтән бер өлеше үткәч уку яхшырак. Бу инде бездәге җәйгә кагылмый. Чөнки бездә җәен төн бик кыска. Әмма ястүне артык сузу, мәсәлән, сәхәр вакытына калдыру – ансы инде мәкрүһ санала. Ягъни намаз үзе дөрес булса да, гөнаһ була.

Шулай итеп намазның вакыты иркен: кергән вакытыннан чыккан вакытына хәтле укылса, ул намаз дөрес була. Ләкин шушы дөрес вакытның яхшырак һәм мәкрүһ вакытлары бар. Шуңа карап намазларны укырга тырышырга кирәк.

2. Җеназа намазында хатын-кызлар катнаша ала, бернинди тыю юк. Җәмәгать намазында ничек, шул рәвештә басалар. Әмма хатын-кызларга җеназага ияреп зиярәтка бару тыела. Әгәр җеназа намазын мәчет яки өй ишек алдында укысалар, анда хатын-кызлар да катнаша ала. Һәм ул дөрес була, катнашучылар саваплы була, әгәр имам артына оеп ирләрдән соң артка басып укысалар. Бездә инде андый гадәт булмаса да, ул шәригать буенча дөрес.

3. Имам мәхәлләдә җәмәгать, җомга намазларын укытыр, дини мәрәсимнәрне – никахлар, исем кушулар, җеназа намазларын башкарыр өчен сайлана. Мондый эшләрне хатын-кызлар эшләми. Хатын-кыз имам булмый, никах укымый, балага исем куша алмый. Чөнки аңа азан әйтү тыела. Шуңа күрә дә, һәм инде ул Устав буенча да шулай, имамны даими мәчеткә йөрүче кешеләр сайлый. Намазны хатын-кызлар өйдә укырга тиешләр. Мәчеткә инде аларга ире яки мәхрәме белән бару рөхсәт ителсә дә, хатын-кызларның өйдә укуы хәерлерәк. Шуңа күрә дә хатын-кызларның намаз уку урыны өйдә була. Имам сайлаганда хатын-кызлар катнашмаска тиеш.

***Укучыбыз сорауларына җавапны шәригать белгече Рәфыйк хәзрәт Миннеәхмәт бирде.***

# “Әл-Әкъса” мәчетенә сәяхәт



Дөньяда мәчетләр күп, аларның төгәл санын бер Аллаһ кына белә. Ләкин мәчетләрнең саны үзгәреп тора. Яңа мәчетләр төзелә, ә иkенчеләре төрле сәбәпләр белән юкка чыга. Мәсәлән, соңгы ярты ел эчендә генә Башкортостанда 2 мәчет юкка чыкты. Берсе Баймак районы Мулдакай авылында борынгы мәчет ут чыгып тулысынча янып бетте. Икенчесе безнең Учалы районы Юлдаш авылының шулай ук борынгы мәчете искереп җимерелү хәленә җиткәч, тиз генә җимереп нигезенә хәтле сүтеп ыргыттылар.

Сугышлар барган төрле илләрдә мәчетләр җимерелә, юкка чыгалар.

Мәчетләр Аллаһ йорты булып санала. Мәчеткә килгән һәр кеше Аллаһ кунагы. Ә мәчет эшләре белән шөгыльләнгән кешеләр Аллаһның хезмәтчесе булалар.

Мәчеткә намаз укырга килгән кеше өендә укыган намазга караганда 27 мәртәбә артык савап ала.

Билгеле, мәчетләр төрле проект буенча төзеләләр. Тышкы күренеше белән матурлары була, гади күренештәгеләре дә күпләр. Намаз укырга исәпләнгән заллары да төрле зурлыкта.

Дөньядагы мәчетләр арасында тарихи яктан кыйммәтле булып саналган 3 мәчет бар. Аларның икесе Сәгуд Гарәбстанында Мәккә шәһәрендә “Әл-Харам” мәчете һәм Мәдинә шәһәрендә Пәйгамбәребез мәчете. Ә өченче мәчет “Әл-Әкъса” Иерусалим шәһәрендә. “Әл-Әкъса” мөселманнарның дөньяда борынгы изге мәчете. Ул шәһәрнең Көнчыгыш ягында урнашкан. “Әл-Әкъса” атамасын безнең телгә әйләндергәндә “ерактагы мәчет” дигәнне аңлата. “Әл-Әкъса” Мәккәдәге “Әл-Харам” мәчетеннән ерак булу сәбәпле шулай дип атап йөртелә. Заманында бу ике мәчет арасы атлы кеше өчен бер айлык юл булып исәпләнгән. “Әл-Әкъса” күп еллар дәвамында төзелә. Төзергә башлаган елын тарих галимнәре ачыклый алмыйлар. Ә төзелеп беткән елын 705 нче ел дип аңлаталар. Тәүге елларда бу мәчет төрле исемнәрдә була.

“Әл-Әкъса” мәчетенең туган җире — Фәләстыйн иле. Күп еллар мәчет Фәләстыйн мөселманнарына хезмәт итә. Ләкин 1948-49 елларда хәрби көч кулланып Фәләстыйн җиренең бер өлешен Израиль яһүдләре яулап ала. Фәләстыйн ике өлешкә бүленә - Көнбатыш һәм Көнчыгыш якларына. Мәчет “Әл-Әкъса” Израиль ягында кала.

Израиль яһүдләре мөселманнарны һәм мәчетне яраталар дип әйтеп булмый, аларга дошманлык күзе белән карыйлар. Күршедә булган Иордания хөкүмәте Фәләстыйн мөселманнарының хәлен аңлап ярдәмгә килә. Израиль хөкүмәте белән килешү төзеп “Әл-Әкса” мәчетен тотуны Иордания үз өстенә ала.

Хәзерге көндә “Әл-Әкъса” мәчетен тулысынча Иордания дини хезмәткәрләре идарә итә: намаз укыталар, халыкка дини вәгазь сөйлиләр, мәчетнең һәр төрле башка эшләрен башкаралар. Мәчетнең бөтен акча чыгымнарын Иордания хөкүмәте үз өсенә ала. Мәчеткә керү-чыгуны да Иордания солдатлары контрольдә тота. Теләгән бар кеше дә мәчеткә үтә алмый. Һәр кешене ныклап тикшереп, карап мәчеткә үткәрәләр, бигрәк тә шикләрәк кеше килсә. Мәсәлән, безнең Учалы шәһәреннән бер ир кардәшебез “Әл-Әкъса” мәчетен күрәсе килеп Израильгә барган. Мәчеткә барып җиткән, ләкин солдатлар аны үткәрмәгәннәр. Мәчетнең тышкы күренешен, күркәм манарасын койма аша күргән. Кардәшебезне мәчеткә үткәрмәү генә түгел, аны Израиль төрмәсенә ябып куялар. Ике тәүлек утырып чыга.

Уфадан кыз бала (12 яшь) әнисе белән чакыру буенча Израильгә барганнар. Намаз укырга “Әл-Әкъса”га килгәннәр. Солдатлар әнисен мәчеткә үткәргәннәр, ә кызын үткәрмәгәннәр. Шуннан әлеге кыз читкәрәк басып кычкырып Коръән укый башлаган. Солдатлар бу кызны мәчеткә үткәреп җибәргәннәр.

Учалыда яшәгән Казан шәһәре егете белән үткән 2016 ел “Әл-Әкъса” мәчетен күрер өчен Израильгә киттек. Иерусалим шәһәренә әйбәт барып җиттек. “Әл-Әкъса” га бару җомга көнгә туры килде. 5 мең кешегә исәпләнгән мәчеттә буш урын юк иде. Хатын-кызларга бүлеп эшләнгән аерым урын юк. Аларга ишектән кергәч тә уң якта мәчетнең арткы бер почмагында урын каралган. Хатын-кызлар күп түгел иде, Иерусалимнеке түгелләр, ә читтән — башка илләрдән килгән хатын-кызларга охшаганнар иде.

Мәчетнең намаз уку залы зур, 11 зур, биек ишекләре бар. 7 ишеге намаз укыган вакытта да ачык тордылар. Тышта көн эссе, мәчет эчендә күп санлы вентиляторлар гүләп эшләп торалар. Мәчет эчендә китаплар куелган, 2 катлы 20 кәштә бар. Санап чыктым: һәр кәштәдә йөзәр Коръән, хәдис китаплары. Мәчеткә кергән күп кешеләр иң башта Коръән китабын алалар, залда намазга урын алалар, Коръән укый башлыйлар. Бер-бере белән очрашып, күрешеп, сөйләшеп торган күренешләр юк. Мәчет тәртибе югары дәрәҗәдә, намаз залын аркылы-буйга йөрү сирәк күренеш.

Намаз укуда аермалар бар. Бездәге җомга намазының баштагы 4 рәкәгатен анда 2 рәкәгать кенә укыйлар. Намаз укып тәмам булгач Коръән уку, күрешүләр юк. Мәчет эчендә садака салу тәртибе дә юк. Садака салу өчен урын да билгеле түгел, тартмалар да куелмаган. Намаз залында хатын-кызларның ирләр арасында аралашып йөргәннәре дә күренми. Җомга намазы тәгалләнү белән халык бик тиз таралып бетте.

Мәчетнең азан тавышы көчле, еракларга тарала. Мәсәлән, безнең кунакханә мәчеттән 3 чакрым ераклыта иде, азан һәрчак ишетелеп торды.

Иерусалим үзенең байлыгы белән аерылып тора. Андагы байлыкны язып та, сөйләп тә аңлатырга мөмкин түгел, барып кына күрергә кирәк. Коръәннең “Бәни Исраил” сүрәсенең бер аятендә Аллаһ әйтә: “Коддус шәһәренең тирәсен бәрәкәтле иттек.” Коддус хәзерге Иерусалимнең элекке исеме. Иерусалимне Аллаһ бәрәкәтле иткәнгә күрә шәһәрнең җир өсте дә, җир асты да байлыкка баткан. Җир өстендә меңләгән магазиннар булса, җир астында да ким түгелдер. Җир астында йөрү, сәүдә итү уңайлы. Чөнки көндез җир өстендә бик эссе, ә җир астында җиләс, эссе түгел. Җир асты магазиннарының төзелешенә игътибар иттек.Тирән итеп әллә ничә чакрым буена чокыр (траншея) казылган. Аның ике ягында магазиннар. Чокырның өсте бетон белән капланган, анда агачлар, урман үсеп утыра. Мәчет “Әл-Әкъса”га шушы җир асты магазиннары аша 2 чакрым юлны үтеп, мәчет янында җир өстенә чыктык. Мәчеттән кайтканда җир астында адашып йөрдек, шәһәргә - җир өстенә чыга алмыйча. Сорашырга андагы халык телен белмибез, алар безнең телне белмиләр. Бары тик “такси” сүзен алар да, без дә беләбез. Шул бер сүз безне шәһәргә таксига алып барып җиткерде.

Күп гасырлар дәвамында Иерусалим ничә мәртәбә яһүдләр тарафыннан яулап алынды, җимерелде, яңадан аякка басты. Вакытлар булды: Иерусалим христианнарның изге шәһәре дип исәпләнде. “Әл-Әкъса” мәчетен яһүдләр чиркәү итеп кулландылар, хәрби кораллар саклау келәте итеп тоттылар. 638 елны гарәп гаскәрләре Иерусалимне яңадан яулап алдылар. “Әл-Әкъса” яңадан мөселманнар мәчетенә әйләнде. Иерусалим Ислам үзәге була башлады. Ләкин 1099 елны яһүдләр яңадан күп көч белән һөҗүм итеп Иерусалимне басып алдылар. “Әл-Әкъса” яңадан христианнар үзәгенә әйләнде.

Тәре йөртүчеләрнең хөкеме озакка бармады. 1187 елны Сәләхет-дин исемле мөселманнар башлыгы, көч туплап, яңадан Иерусалимне яулап ала, “Әл-Әкъса” яңадан мәчеткә әйләнә. Ислам дине яңадан күтәрелә башлый.

Бүгенге көндә ( автор Иерусалимдә булган 2016 ел күздә тотыла) Иерусалимнең зур бер урамы “Сәләхет-дин” исемен йөртә.

“Әл-Әкъса” күп мәртәбә төрле авыр сынаулар үтте. Яһүдләр мәчеткә тынычлык бирмәскә тырышалар. Ут та төртәләр, корал белән дә мәчеткә кереп ут ачалар, кешеләрне үтерәләр, яралыйлар.

1969 елның 21 августында мәчетне яндыралар, зур зыян килә. Иордания хөкүмәте ярдәм итеп, мәчетне тиз арада аякка бастыралар.

1982 елның 11 апрелендә көндезге намаз укыган вакытта Израиль хәрби формасы кигән бер офицер мәчеткә үтеп, намаз укучыларга автоматтан ут ача. Күп кенә кешеләр үләләр һәм яраланалар.

Бүгенге (2016) көндә дә Израиль яһүдләре мәчеткә тынычлык бирмиләр. Яһүдләрнең бер төркеме мәчетне шартлатып җир йөзеннән юкка чыгарырга өндиләр. Әлбәттә, яһүдләрнең “Әл-Әкъса” мәчетен юкка чыгарырга тырышулары гарәп илләрендә мөселманнарның Израильгә каршы ризасызлыкларын белдереп хәрәкәт ачырга мәҗбүр итә.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтеп калдырган хәдис бар. Әгәр дә сәфәрдә өч изге мәчетнең берсендә намаз укырга ниятегез булмаса, андый сәфәргә чыкмагыз. Кайда булса да салынган яңа мәчетләрне карар өчен, анда намаз укыр өчен юлга чыкмагыз.

Яңа мәчетләрне барып карау өчен, күрер өчен сәяхәт тәкъдим ителми. Ә Мәккәдәге “Әл-Харам” мәчетенә, Мәдинәдәге Пәйгамбәребез мәчетенә, Иерусалимдәге “Әл-Әкъса” мәчетенә бару, анда намазлар уку мөмкинчелеге булган һәр мөселманның изге бурычы булып санала.

Әлеге вакытта Сәгуд Гарәбстанында Мәдинә шәһәреннән Мәккәгә кадәр тимер юлы салына. Тиз йөрешле поездлар 3 урында (Рабит, Җиддә, аэропорт) туктап автобуслар белән чагыштырганда 2 мәртәбә тизрәк барып җитәчәк. Автобуслар бу араны 9 сәгать үтә. Ә поезд 4 сәгать ярым барачак.

2018 елны тимер юлы эшли башлаячак. Тимер юлының исеме “Әл-Харамейн.” Халык яшәгән авыллар янынннан үткәндә поездларның тавышын киметү тәртибе каралган.

Хаҗ кылырга безнең яклардан ел саен күп кеше йөри. Хаҗ кылган кешеләр барсы да “Әл-Харам” мәчетендә һәм Мәдинәдә Пәйгамбәребез мәчетендә булалар. Ләкин безгә мөселманнарга 3 мәчеттә булырга тәкъдим ителә. Өченче мәчет булып “Әл-Әкъса” санала. Хаҗдан әйләнеп кайткан кешеләр “Әл-Әкъса”га барырга ашыкмыйлар, бармыйлар да. Хаҗга караганда “Әл-Әкъса”га бару күпкә җиңелрәк. Тик барырга теләк кенә кирәк. Хәзерге вакытта юл тыныч, куркыныч түгел. Элекке үткән елларда Израильдә һәр вакытта тынычлык булмады, сугыш булды. Ул якларда юл йөреше уңайлы хәзер. Юллар матур. Мәсәлән, Иерусалим белән аэропорт арасы 64 чакрым. 64 чакрым буена юл өстеннән 5 рәт лампочкалар төнлә янып тора, юл өсте якты, көндезгә кебек.

**Исмәгыйль хәзрәт Игъезянов**
**Башкортостанның Учалы шәһәре.**

# Намаз вакытлары

| Милади Июль | Көн исеме | Шәүвал, Зөлкагъдә | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Чаллы | Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Чаллы | Казан | Кояш чыга Уфа | Чаллы | Казан | Завал Уфа | Чаллы | Казан | Өйлә Уфа | Чаллы | Казан | Икенде Уфа | Чаллы | Казан | Ахшам Уфа | Чаллы | Казан | Ястү Уфа | Чаллы | Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шм | 7 | 02.42 | 00.50 | 01.02 | 03.12 | 01.20 | 01.32 | 04.42 | 02.50 | 03.02 | 13.17 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.04 | 17.21 | 17.34 | 21.56 | 20.17 | 20.31 | 23.26 | 21.47 | 22.01 |
| 2 | Як | 8 | 02.42 | 00.50 | 01.03 | 03.12 | 01.20 | 01.33 | 04.42 | 02.50 | 03.03 | 13.17 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.04 | 17.21 | 17.34 | 21.56 | 20.17 | 20.30 | 23.26 | 21.47 | 22.00 |
| 3 | Дш | 9 | 02.43 | 00.51 | 01.04 | 03.13 | 01.21 | 01.34 | 04.43 | 02.51 | 03.04 | 13.18 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.20 | 17.34 | 21.55 | 20.16 | 20.30 | 23.25 | 21.46 | 22.00 |
| 4 | Сш | 10 | 02.44 | 00.52 | 01.05 | 03.14 | 01.22 | 01.35 | 04.44 | 02.52 | 03.05 | 13.18 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.20 | 17.33 | 21.55 | 20.16 | 20.29 | 23.25 | 21.46 | 21.59 |
| 5 | Чш | 11 | 02.42 | 00.50 | 01.02 | 03.12 | 01.20 | 01.32 | 04.42 | 02.50 | 03.02 | 13.17 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.04 | 17.21 | 17.34 | 21.56 | 20.17 | 20.31 | 23.26 | 21.47 | 22.01 |
| 6 | Пж | 12 | 02.42 | 00.50 | 01.03 | 03.12 | 01.20 | 01.33 | 04.42 | 02.50 | 03.03 | 13.17 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.04 | 17.21 | 17.34 | 21.56 | 20.17 | 20.30 | 23.26 | 21.47 | 22.00 |
| 7 | Жм | 13 | 02.43 | 00.51 | 01.04 | 03.13 | 01.21 | 01.34 | 04.43 | 02.51 | 03.04 | 13.18 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.20 | 17.34 | 21.55 | 20.16 | 20.30 | 23.25 | 21.46 | 22.00 |
| 8 | Шм | 14 | 02.44 | 00.52 | 01.05 | 03.14 | 01.22 | 01.35 | 04.44 | 02.52 | 03.05 | 13.18 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.20 | 17.33 | 21.55 | 20.16 | 20.29 | 23.25 | 21.46 | 21.59 |
| 9 | Як | 15 | 02.45 | 00.53 | 01.06 | 03.15 | 01.23 | 01.36 | 04.45 | 02.53 | 03.06 | 13.18 | 11.34 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.02 | 17.20 | 17.33 | 21.54 | 20.15 | 20.28 | 23.24 | 21.45 | 21.58 |
| 10 | Дш | 16 | 02.46 | 00.54 | 01.07 | 03.16 | 01.24 | 01.37 | 04.46 | 02.54 | 03.07 | 13.18 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.02 | 17.20 | 17.33 | 21.53 | 20.14 | 20.28 | 23.23 | 21.44 | 21.57 |
| 11 | Сш | 17 | 02.47 | 00.55 | 01.08 | 03.17 | 01.25 | 01.38 | 04.47 | 02.55 | 03.08 | 13.18 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.02 | 17.19 | 17.33 | 21.53 | 20.14 | 20.27 | 23.23 | 21.44 | 21.56 |
| 12 | Чш | 18 | 02.48 | 00.56 | 01.09 | 03.18 | 01.26 | 01.39 | 04.48 | 02.56 | 03.09 | 13.18 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.02 | 17.19 | 17.32 | 21.52 | 20.13 | 20.26 | 23.22 | 21.43 | 21.55 |
| 13 | Пж | 19 | 02.49 | 00.58 | 01.10 | 03.19 | 01.28 | 01.40 | 04.49 | 02.58 | 03.10 | 13.19 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.02 | 17.19 | 17.32 | 21.51 | 20.12 | 20.25 | 23.21 | 21.42 | 21.54 |
| 14 | Жм | 20 | 02.50 | 00.59 | 01.12 | 03.20 | 01.29 | 01.42 | 04.50 | 02.59 | 03.12 | 13.19 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.01 | 17.18 | 17.31 | 21.50 | 20.11 | 20.24 | 23.20 | 21.41 | 21.53 |
| 15 | Шм | 21 | 02.51 | 01.00 | 01.13 | 03.21 | 01.30 | 01.43 | 04.51 | 03.00 | 03.13 | 13.19 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.01 | 17.18 | 17.31 | 21.49 | 20.10 | 20.23 | 23.19 | 21.40 | 21.52 |
| 16 | Як | 22 | 02.53 | 01.01 | 01.14 | 03.23 | 01.31 | 01.44 | 04.53 | 03.01 | 03.14 | 13.19 | 11.35 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.00 | 17.17 | 17.31 | 21.48 | 20.09 | 20.22 | 23.18 | 21.39 | 21.51 |
| 17 | Дш | 23 | 02.54 | 01.03 | 01.16 | 03.24 | 01.33 | 01.46 | 04.54 | 03.03 | 03.16 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.00 | 17.17 | 17.30 | 21.47 | 20.08 | 20.21 | 23.17 | 21.38 | 21.50 |
| 18 | Сш | 24 | 02.55 | 01.04 | 01.17 | 03.25 | 01.34 | 01.47 | 04.55 | 03.04 | 03.17 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.59 | 17.16 | 17.29 | 21.46 | 20.06 | 20.20 | 23.16 | 21.36 | 21.49 |
| 19 | Чш | 25 | 02.57 | 01.06 | 01.18 | 03.27 | 01.36 | 01.48 | 04.57 | 03.06 | 03.18 | 13.19 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.59 | 17.16 | 17.29 | 21.45 | 20.05 | 20.19 | 23.15 | 21.35 | 21.47 |
| 20 | Пж | 26 | 02.58 | 01.07 | 01.20 | 03.28 | 01.37 | 01.50 | 04.58 | 03.07 | 03.20 | 13.20 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.58 | 17.15 | 17.28 | 21.44 | 20.04 | 20.17 | 23.14 | 21.34 | 21.46 |
| 21 | Жм | 27 | 02.59 | 01.08 | 01.21 | 03.29 | 01.38 | 01.51 | 04.59 | 03.08 | 03.21 | 13.20 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.58 | 17.14 | 17.28 | 21.42 | 20.03 | 20.16 | 23.12 | 21.33 | 21.45 |
| 22 | Шм | 28 | 03.01 | 01.10 | 01.23 | 03.31 | 01.40 | 01.53 | 05.01 | 03.10 | 03.23 | 13.20 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.57 | 17.14 | 17.27 | 21.41 | 20.01 | 20.15 | 23.11 | 21.31 | 21.43 |
| 23 | Як | 29 | 03.02 | 01.12 | 01.24 | 03.32 | 01.42 | 01.54 | 05.02 | 03.12 | 03.24 | 13.20 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.56 | 17.13 | 17.26 | 21.40 | 20.00 | 20.13 | 23.10 | 21.30 | 21.42 |
| 24 | Дш | 1 | 03.04 | 01.13 | 01.26 | 03.34 | 01.43 | 01.56 | 05.04 | 03.13 | 03.26 | 13.20 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.56 | 17.12 | 17.25 | 21.38 | 19.58 | 20.12 | 23.08 | 21.28 | 21.40 |
| 25 | Сш | 2 | 03.05 | 01.15 | 01.28 | 03.35 | 01.45 | 01.58 | 05.05 | 03.15 | 03.28 | 13.20 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.55 | 17.11 | 17.25 | 21.37 | 19.57 | 20.10 | 23.07 | 21.27 | 21.38 |
| 26 | Чш | 3 | 03.07 | 01.16 | 01.29 | 03.37 | 01.46 | 01.59 | 05.07 | 03.16 | 03.29 | 13.20 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.54 | 17.11 | 17.24 | 21.35 | 19.55 | 20.08 | 23.05 | 21.25 | 21.37 |
| 27 | Пж | 4 | 03.09 | 01.18 | 01.31 | 03.39 | 01.48 | 02.01 | 05.09 | 03.18 | 03.31 | 13.20 | 11.36 | 11.49 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.53 | 17.10 | 17.23 | 21.34 | 19.54 | 20.07 | 23.04 | 21.24 | 21.35 |
| 28 | Жм | 5 | 03.10 | 01.20 | 01.33 | 03.40 | 01.50 | 02.03 | 05.10 | 03.20 | 03.33 | 13.21 | 11.36 | 11.50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.52 | 17.09 | 17.22 | 21.32 | 19.52 | 20.05 | 23.02 | 21.22 | 21.34 |
| 29 | Шм | 6 | 03.12 | 01.21 | 01.34 | 03.42 | 01.51 | 02.04 | 05.12 | 03.21 | 03.34 | 13.21 | 11.36 | 11.50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.51 | 17.08 | 17.21 | 21.31 | 19.50 | 20.04 | 23.01 | 21.20 | 21.32 |
| 30 | Як | 7 | 03.14 | 01.23 | 01.36 | 03.44 | 01.53 | 02.06 | 05.14 | 03.23 | 03.36 | 13.21 | 11.36 | 11.50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.51 | 17.07 | 17.20 | 21.29 | 19.48 | 20.02 | 22.59 | 21.18 | 21.30 |
| 31 | Дш | 8 | 03.15 | 01.25 | 01.38 | 03.45 | 01.55 | 02.08 | 05.15 | 03.25 | 03.38 | 13.22 | 11.36 | 11.50 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.50 | 17.06 | 17.19 | 21.27 | 19.47 | 20.00 | 22.57 | 21.17 | 21.28 |

## V Республика ифтары 15 июньдә Теннис академиясендә уздырыла



Ифтарда 10 меңгә якын кеше катнашыр дип көтелә. Ифтар мәҗлесен ТР Диния нәзарәте, РФ Мөселман эшкуарлары ассоциациясе,"Казан-Арена" стадионы дирекциясе оештыра. Катнашучыларны дин әһелләренең вәгазьләре, мөнәҗәтләр, Коръән укып, догалар кылу, җәмәгать намазы һәм ифтар ашы көтә.

Әлеге хәйрия чарасы Татарстанда 2013 елдан башлап даимә рәвештә үткәрелә һәм анда республика дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре, Россиянең төрле төбәкләреннән килгән кунаклар, физик мөмкинлекләре чикле кешеләр, ятим балалар катнаша.

Мәгълүм булганча, үткән елларны республика ифтары "Казан-Арена" стадионында оештырылып килде һәм үзенә бер үк вакытта 15 меңгә якын кеше кабул итә ала иде. Июньдә бирелдә Конфедерацияләр кубогы уеннары узачак һәм ул башка максатлардан кулланыла алмаячак. Алдан V Республика ифтарын үткәрү ниятләнгән Үзәк стадион да Кубокта катнашкан командалар өчен күнекмәләр мәйданы булып кулланылачак.


### Кабер ташлары, чардуганнар ясыйбыз

Бәясе 3 мең сумнан башлана. Срогы – бер атна. Эш көннәрендә иртәнге 9 дан кичке 5 кә кадәр, шимбә иртәнге 9 дан көндезге 2 гә кадәр (якшәмбе ял) түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итәргә: Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Үзәк ур., 70 Тел. 89375991557.



**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 8 июнь 16 сәг. фактта 8 июнь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**